**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4178**
**14.08.2019**

«Татарстан кроссы – 2019» республика массакүләм ярышларын үткәрү көнендә Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертү турында

«Татарстан кроссы – 2019» республика массакүләм ярышлары үткәрелү уңаеннан, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юллар эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ санлы Федераль законның 30 маддәсе, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ санлы Законының 27 маддәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 нче карары белән расланган Региональ яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибе, шәһәр Уставының 41 маддәсе 9 пунктының 24.1 пунктчасы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2019 елның 21 сентябрендә 9.30 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертергә:

1) Чулман проспекты буенча Тантаналар сараеннан «Чулман проспекты» тукталышына кадәр автомобиль юлы участогында;

2) Хәсән Туфан проспекты буенча ике юнәлештә дә Раскольников урамыннан Чулман проспектына кадәр автомобиль юлы участогында.

2. Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенең ЮХИДИ бүлегенә транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорында гражданнар иминлеген, җәмәгать тәртибен һәм юл хәрәкәтен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгыруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә:

1) әлеге карарны «Интернет» челтәрендә ведомствоның рәсми сайтында урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына җибәрергә;

2) транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне һәм автомобиль юлларын ябу өчен кирәкле йөк транспорты бирүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин